| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

«27» февраль 2026 ел Алабуга шәһәре № 43

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советынвң «Алабуга муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контроле турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2023 елның 7 сентябрендәге 274 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 29 декабрендәге 548-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» Федераль законның 29 һәм 65 статьялары нигезендә һәм Алабуга шәһәр прокуроры протестын караганнан соң, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советы

КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының 2023 елның 7 сентябрендәге 274 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контроле турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.9.1 пунктның 5 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) контрольдә тотыла торган затларның, аларның вәкилләренең, үзеннән-үзе җайга салына торган оешма вәкилләренең монда булуына каршылык күрсәтмәскә, әгәр контрольдә тотылучы зат өчен үзеннән-үзе җайга салына торган оешмада мәҗбүри әгъза булу каралган булса, ә контрольдә тотылучы затларның, аларның вәкилләренең ризалыгы белән Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилнең яисә аның җәмәгать вәкилләренең контроль чаралар (контроль органнарының тикшереп торылучы затлар белән үзара хезмәттәшлеге таләп ителми торган контроль чаралардан тыш) үткәргәндә катнашуы каралган булса һәм 248-ФЗ номерлы Федераль законда һәм әлеге Нигезләмәнең 3.3 пунктында каралган консультацияләр бирүне гамәлгә ашырырга;».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны җир-мөлкәт мөнәсәбәтләре һәм табигатьтән файдалану мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Рәис урынбасары А.В. Косов